ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәгә (2016 елның 21 июнендәге 1296-V ДС номерлы, 2016 елның 15 декабрендәге 1545-V ДС номерлы, 2019 елның 16 октябрендәге 98-VI ДС номерлы, 2020 елның 17 апрелендәге 365-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 пунктта «Идарәләр башлыклары,» сүзләреннән соң «Эшләр идарәчесе,» сүзләрен өстәргә, «идарәләр башлыклары урынбасарлары,» сүзләреннән соң «Эшләр идарәчесе урынбасарлары,» сүзләрен өстәргә;

2) 15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«15. Аппаратның Эшләр идарәсе Дәүләт Советы депутатларын һәм Аппарат хезмәткәрләрен мәгълүмати-технологик, матди-техник, хуҗалык, транспорт, социаль-көнкүреш, мәдәни һәм медицина ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, Дәүләт Советы бинасында янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлүен тәэмин итә, Дәүләт Советының товарларда, эшләрдә һәм хезмәтләр күрсәтүдә ихтыяҗларын билгели, дәүләт сатып алуларын оештыра, шулай ук, Дәүләт Советы Аппаратының Административ

регламентына һәм Аппаратның Эшләр идарәсе турындагы нигезләмәгә таянып, башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән функцияләрне гамәлгә ашыру максатларында Эшләр идарәсе Дәүләт Советы Аппараты исеменнән дәүләт контрактлары, физик һәм юридик затлар белән граждан-хокук шартнамәләре төзи, ә Эшләр идарәчесе аларны имзалый.»;

3) $19^{1}$ пунктта «, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне һәм Дәүләт Советы биналарының янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы затларның эшчәнлеген тикшереп торуны тәэмин итә» сүзләрен «таләпләре үтәлүне тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2021 елның 18 ноябре
№ 1192-VI ДС